**Поезд**

1) Поезд, поезд, поезд!
   Кайларга барасың?
   Поезд, поезд, поезд,
   Кая ашыгасың?
   Поезд, поезд, поезд,
   Кайларда йөрисең?
   Поезд, поезд, поезд,
   Нәрсәләр эшлисең?

Ту-ту, ту - ту, ту - ту – ту!
Чух-чух, чух-чух, чух-чух-чух!

2) Мин барам еракларга,
   Шәһәрләр-авылларга.
   Кешеләрне озатам
   Кирәкле урыннарга.
   Юлга кермә, тапталма!
   Поезд бит бик тиз бара.
   Ашыгып, тимер юлдан
   Һәрчак йөгерә-чаба!

Ту-ту, ту - ту, ту - ту – ту!
Чух-чух, чух-чух, чух-чух-чух!

3) Поезд, поезд, поезд!
   Мине дә утырт әле.
   Поезд, поезд, поезд!
   Еракларга илт әле.
   Поезд, поезд, поезд!
   Дөньяны гизим әле.
   Поезд, поезд, поезд,
   Күп җирләр күрим әле.

Ту-ту, ту - ту, ту - ту – ту!
Чух-чух, чух-чух, чух-чух-чух!

4) Станциядә туктагач,
   Утыр әйдә вагонга.
   Машинист гудок биргәч,
   Поезд юлга кузгала.
   Юлга кермә, тапталма.
   Поезд бит бик тиз бара.
   Ашыгып, тимер юлдан
   Һәрчак йөгерә-чаба!